МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

Тел. (843) 221-37-01, Факс 221-37-37,E-

ПРИКАЗ БОЕРЫК

15.05.2018 Казан ш. № 262-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе турында нигезләмә раслау турында

Россия Федерациясе Урман кодексына дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру өлешендә кертелгән үзгәрешләргә туры китереп, **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2014 елның 24 апрелендәге 150-осн номерлы боерыгын.

3. Юридик бүлеккә дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми бастырып чыгару өчен әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Ә.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы Урман
хуҗалыгы министрлыгының
15.05.2018 елның № 262-осн
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе турында нигезләмә

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Сатулар оештыручы) боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яисә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар (алга таба – сатулар) оештыру максатларында төзелә.

2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә 2006 елның 4 декабрендәге 20-ФЗ номерлы федераль закон – Россия Федерациясе Урман кодексына, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Сатулар оештыручы Комиссиягә түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыру вәкаләтен бирә:

3.1. сатулар уздыру турында кабул ителгән карар нигезендә Россия Федерациясе Урман кодексының 78 статьясының 1 өлеше һәм $80^1$ статьясының 1, 2 өлешләре нигезендә сатулар уздырылуы турында хәбәрләмә әзерләү;

3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатулар уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рәсми сайтта (www.torgi.gov.ru) (алга таба – сатуларның рәсми сайты) сатулар уздырылуы турында хәбәрләмә урнаштыру, түбәндәге срокларда:

3.2.1. дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру көненә кадәр кимендә утыз биш көн алдан; урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру көненә кадәр кимендә егерме көн алдан;

3.2.2. агач материалы әзерләү өчен дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына ачык конкурс уздыру көненә кадәр кимендә алтмыш биш көн алдан;

3.2.3. сатулар уздырылуы турында мәгълүмат мәнфәгатьле барлык затлар өчен танышып чыгу өчен мөмкинлекле булырга тиеш;

3.3. сатуларда катнашу өчен заявкаларны кабул итү урынын, датасын, кабул итә башлау һәм тәмамлау вакытын, сатуларда катнашучыларны билгеләү урынын, датасын һәм вакытын, сатуларны уздыру һәм йомгак ясау датасын һәм урынын билгеләү;

3.4. мөрәҗәгать итүчеләрдән сатуларда катнашу өчен заявкалар һәм аңа теркәлә торган документларны заявкалар кабул итү беркетмәсен алып барып кабул итү, аларның саклануын, шулай ук заявкалар тапшырган затлар турында белешмәләрнең, шулай ук заявкаларның булуы яки булмавы турында мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итү;

3.5. Россия Федерациясе Урман кодексының 78 статьясының 10, 11 өлешләренә туры китереп, аукцион предметының башлангыч бәясен (аренда өчен түләүнең башлангыч бәясен яки әзерләнә торган агач материалының башлангыч бәясен), аукцион предметының башлангыч бәясен арттыру зурлыгын («аукцион адымы»н) билгеләү;

Россия Федерациясе Урман кодексының $80^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән криетрийлар нигезендә һәм тәртиптә уздырыла торган конкурста катнашучыларның конкурс тәкъдимнәрен бәяләү;

3.6. мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларның рәсмиләштерелүе дөрес булу-булмавын тикшерү;

3.7. мөрәҗәгать итүчеләрне сатуларда катнашучылар итеп тану турында яисә Россия Федерациясе Урман кодексының 78 статьясының 18 өлешендә, $80^1$ статьясының 21 өлешендә билгеләнгән нигезләрдә сатуларга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләргә кабул ителгән кара турында хәбәр итү;

3.8. алдан түләү өлеше суммасын билгеләү, законнарда билгеләнгән тәртиптә алдан түләү өлешләренең килүен һәм кайтарып бирелүен тикшерү;

3.9. сатуларда җиңүчене билгеләү яисә Россия Федерациясе Урман кодексының 79 статьясының 6 өлеше, $80^2$ статьясының 9 өлеше нигезендә сатуларны узмаган дип тану;

3.10. сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмә рәсмиләштерү;

3.11. сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмә имзаланган көннән башлап бер көн эчендә сатуларның рәсми сайтында сатуларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру;

3.12. сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куелган датадан өч эш көне эчендә сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмәне – сатуларда җиңүчегә, калган катнашучыларга беркетмәнең күчермәсен җибәрү;

3.13. сатулар уздыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән бәхәсле хәлләрне карау.

## II. Комиссия эшчәнлеген оештыру

4. Комиссия коллегиаль орган булып тора, үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясе Урман кодексының 78 статьясының 1 өлеше һәм $80^1$ статьясының

1, 2 өлешләре нигезендә Сатулар оештыручының сатуларны уздыру турында карарына туры китереп гамәлгә ашыра.

5. Комиссиянең шәхси составы, шул исәптән рәисе, рәис урынбасары, Комиссия әгъзалары һәм сәркатибе Сатулар оештыручы боерыгы нигезендә раслана. Комиссия кимендә биш кешелек санда формалаша. Комиссия составын үзгәртү Сатулар оештыру боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Комиссия хокуклы:

сатулар уздыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән бәхәсле хәлләрне хәл итү өчен, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә конкурс тәкъдимнәренә эксперт бәясен алуны тәэмин итү максатларында экспертлар җәлеп итү турында карар кабул итәргә;

рәсми чыганаклардан, шул исәптән Татарстан Республикасы Арбитраж суды яисә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе рәсми сайтыннан файдалану юлы белән мөрәҗәгать итүчегә карата банкротлык процедураларының гамәлгә ашырылуы турында белешмәләр алырга;

әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча утырышлар уздырырга. Комиссия утырышы, барча әгъзаларының гомуми исәбеннән кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы хәл иткеч була.

7. Комиссия бурычлы:

сатуларны оештыру һәм уздыру буенча законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

сатуларны уздыру һәм аның нәтиҗәләре турында түләү алмыйча барча мәнфәгатьле затларның мәгълүмат ала алуын тәэмин итәргә;

Сатулар оештыручы тарафыннан йөкләнгән функцияләрне тиешле рәвештә гамәлгә ашырырга.

8. Комиссия рәисе:

Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә һәм Комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен персональ җаваплы була;

Комиссия рәисе урынбасарына, сәркатибенә, әгъзаларына сатулар уздыру өчен документация әзерләргә куша;

сатуларны ачып җибәрә, утырышны тулы хокуклы дип игълан итә яисә аны Комиссия әгъзалары тиешле санда булмауга бәйле рәвештә күчерә;

катнашучыларны сатуларны уздыру шартлары белән таныштыра;

сатуларда җиңүчене яисә сатуларны узмаган дип игълан итә;

сатуларны уздыру көнендә сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмәгә Сатулар оештыручы исеменнән кул куя.

9. Комиссия рәисе урынбасары:

Комиссия әгъзаларын сатуларны уздыру материаллары белән таныштыра;

Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын башкара.

10. Комиссия эшен оештыруны сәркатип гамәлгә ашыра. Комиссия сәркатибе:

сатулар уздырылуы турында мәгълүмат, сатулар турында документация, сатуларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерли, аларны сатуларның рәсми сайтында урнаштыра;

заявкалар кабул итә һәм сатуларда катнашуга заявкаларны кабул итү беркетмәсен алып бара;

мөрәҗәгать итүчеләргә сатуларга кертү (кертүдән баш тарту) турында хәбәр итә;

сатуларда катнашучыларны теркәүгә алуны алып бара;

сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмә рәсмиләштерә;

алдан түләү өлешләрен кайтарып бирүне тәэмин итә;

Комиссия эшен тәэмин итү өчен кирәкле оештыру-техник холыклы башка эшләрне гамәлгә ашыра.

11. Комиссия әгъзалары:

сатуларны уздыру материаллары белән таныштыруны гамәлгә ашыра;

мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларның рәсмиләштерелүе дөрес булу-булмавын тикшерә;

махсус фикер белдерергә хокуклы, ул язмача формада рәсмиләштерелә һәм сатуларның нәтиҗәләре турында беркетмәгә теркәлә.

## III. Комиссиянең җаваплылыгы

12. Комиссия сатуларны оештыру һәм уздыру өчен законнар нигезендә җаваплы була.

13. Комиссия беркетмәләренә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.